СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

10.07.23 ел№ 34/4

На №__________от______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Князево авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 31 статьялары, Тукай муниципаль районы уставы, «2023 елда җәмәгать фикер алышулары яки халык тыңлаулары үткәрмичә, генераль планнарга һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» 2023 елның 28 январендагы 63 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пункты нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның 14 ноябрендәге 26/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы  Князево авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 16:39-7.63 реестр номерлы 4-4 номерлы транспорт инфраструктурасының (Т) территориаль зонасы чикләрен үзгәртергә.

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы  рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3 Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Ф.М. Камаев